КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 29 декабрь г.Казань № 1728

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2017 елга Татарстан Республикасының медицина оешмаларында Россия Федерациясе гражданнарына мәҗбүри медицина иминияте база программасына кертелмәгән югары технологияле медицина ярдәме күрсәтүне финанслар белән тәэмин итү турында» 2016 ел, 31 декабрь, 1089 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы медицина оешмаларында Россия Федерациясе гражданнарына мәҗбүри медицина иминияте база программасына кертелмәгән югары технологияле медицина ярдәме күрсәтүне финанслар белән тәэмин итү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2017 елга Татарстан Республикасының медицина оешмаларында Россия Федерациясе гражданнарына мәҗбүри медицина иминияте база программасына кертелмәгән югары технологияле медицина ярдәме күрсәтүне финанслар белән тәэмин итү турында» 2016 ел, 31 декабрь, 1089 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 21 март, 175 нче, 2017 ел, 27 декабрь, 1061 нче, 2018 ел, 11 декабрь, 1113 нче, 2018 ел, 29 декабрь, 1282 нче, 2021 ел, 17 март, 141 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы медицина оешмаларында Россия Федерациясе гражданнарына мәҗбүри медицина иминияте база программасына кертелмәгән югары технологияле

медицина ярдәме күрсәтүне финанслар белән тәэмин итү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән акчалар Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына Татарстан Республикасы медицина оешмаларында югары технологияле медицина ярдәме күрсәтүгә план биремен үтәүне финанс белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетына бюджетара трансфертлар бирү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә (алга таба - Фонд, бюджетара трансфертлар).»;

4 һәм 5 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән баш эш итүче – Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы.

Акча Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында ачылган шәхси счет аша тотыла.

5. Бюджетара трансферт акчасы Фонд тарафыннан Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ачылган шәхси счет аша тотыла.»;

7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы финанслауның иң чик күләмнәрен Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре күләмнәре һәм Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан финанслауның иң чик күләмнәрен җиткергәннән соң расланган бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә җиткерә.»;

8 пунктта «Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы» сүзләренә алмаштырырга;

9 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

10 пунктның өченче абзацында «Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы» сүзләренә алмаштырырга;

16 пунктта «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы һәм» сүзләрен төшереп калдырырга, «10» саннарын «15» саннарына алмаштырырга;

18 пунктның беренче абзацында «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы һәм» сүзләрен төшереп калдырырга, «тәэмин итәләр» сүзләрен «тәэмин итә» сүзләренә алмаштырырга;

19 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«19. Әлеге Тәртипнең 18 пунктында күрсәтелгән очракларда медицина оешмаларына бирелгән акчалар бюджетара трансфертлар өлешендә Фондның тиешле таләбе алынган көннән алып 15 көн эчендә Фонд бюджеты керемена кайтарылырга тиеш.

Медицина оешмалары тарафыннан акчаны кире кайтару сроклары бозылганда Фонд бу пунктның беренче абзацында билгеләнгән срок тәмамланган көннән 30 көн эчендә акчаны тиешле бюджетка законнар белән билгеләнгән тәртиптә түләтү буенча чаралар күрә.»;

22 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«субсидиядән файдалану нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешү һәм аларга ирешү максатларында кабул ителгән йөкләмәләр турында.».

2. Бу карар 2024 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин